ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2025 ел Баулы шәһәре №90

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 134 карары белән расланган территориядә җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2023 елның 27 апрелендәге 110 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, «Пространство белешмәләренең милли системасы «Бердәм цифрлы платформасы «Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 7 июнендәге 1040 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 134 номерлы карары белән расланган, территориядә җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2024 елның 27 апрелендәге 24 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1 пунктының 6) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) чикләрендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү гамәлгә ашырыла торган территорияне межалау проекты булмаган очракта җир кишәрлегенең урнашу схемасы.

Җир кишәрлегенең электрон документ рәвешендә урнашу схемасын әзерләү пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин»;

пункт 2.5.2. дополнить подпунктом 4) следующего содержания:

2.5.2 пунктын 4) пунктча белән түбәндәге эчтәлектә өстәргә:

«4) «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә видеоконференцэлемтә форматында электрон формада;

2.13.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризаны «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәте 2.0» мобиль кушымтасы аша электрон рәвештә видеоконференцэлемтә һәм/яисә Бердәм Республика порталының электрон формада җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша хәбәрнамә ала, ул гаризаның җибәрелгән булуын раслый, анда гариза бирүнең теркәү номеры һәм датасы күрсәтелә.»;

3 «административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре...» бүлегендә:

3.3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктлар өстәргә:

«3.3.2.2. «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә видеоконференцэлемтә форматында электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.2.1. Мөрәҗәгать итүче «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә гариза бирү өчен:

Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы (ЕСИА) ярдәмендә махсуслаштырылган программа тәэминатында авторизация уза;

программа тәэминаты интерфейсы аша гаризалар кабул итүне алып баручы КФҮ хезмәткәренә видеошалтырату инициативасы белән чыга;

3.3.2.2.2. КФҮ хезмәткәре, гаризалар кабул итүне алып баручы:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен идентификацияли;

мөрәҗәгать итүче хәбәр иткән мәгълүматларга һәм сайланган хезмәткә нигезләнеп, гаризаның электрон формасын тутыра, шулай ук Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны соратып ала;

гаризаны файл рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә тикшерү һәм имзалау (раслау) өчен тапшыра;

раслаганнан соң Башкарма комитетка гариза һәм документлар пакеты җибәрә.

Шәхесне идентификацияләү мөрәҗәгать итүченең йөзен паспорттагы фотосурәт белән чагыштыру, шулай ук контроль сорауга дөрес җавап бирү юлы белән башкарыла. Сораштыру вакытында дөрес җавап бирелгән очракта шәхесне идентификацияләү уңышлы дип санала.

Гаризаның электрон формасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында билгеләнгән структурага туры килә.

Мөрәҗәгать итүче сайлаган мәгълүмат бирү ысулы буенча система тарафыннан автоматлаштырылган режимда мөрәҗәгать итүчегә документлар кабул итү турында хәбәрнамә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

3.3.2.2.3. 3.3.2.2 пунктчасында билгеләнгән Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып, Башкарма комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты тора.»;

3.5.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2., 3.5.3.пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлеге булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2., 3.5.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, Пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле регламентта пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.3.3.4. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.3 подпунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлеге булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.3 пунктчасында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, Пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле регламентта пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.5.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2., 3.5.3. пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлеге булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.5.2., 3.5.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, Пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле регламентта пространство

белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров